Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИШТУГАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы,
Иштуган т.ю.т.б., Үзәк урамы, 11 йорт
тел. 8 (84362) 4-20-37

Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИШТУГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422050, Республика Татарстан,
П.ж.д.р. Иштуган, ул. Центральная, д. 11
тел. 8 (84362) 4-20-37

isht.sab@tatar.ru

2019 нчы елның 23 нче апреле № 20

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

Татрстан республикасы Саба муниципаль районы
Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнары
тарафыннан күрсәтелүче муниципаль
хезмәтләр исемлеген раслау турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 нчы елның 27 нче июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатында, Татарстан республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче муниципаль хезмәтләр исемлеген расларга.
2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башкарма комитетының 2011 нче елның 26 нчы июнендә кабул ителгән 12 нче номерлы “Җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында” карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/rus/, җирлекнең информацион стендларында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иштуган авыл җирлеге башлыгы: Р. Ш. Галиахметов

Татарстан республикасы Саба муниципаль районы
Иштуган авыл җирлеге башкарма комитетының
2019 нчы елның 23 нче апрелендә кабул ителгән
20 нче номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге

| | |
|---|---|
| 1 | Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару |
| 2 | Документларның күчермәләрен һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау |
| 3 | Нотариаль гамәлләр кылу: васыятьнамә яки ышанычнамәләрне раслау |
| 4 | Белешмәләр (өземтәләр) бирү |
| 5 | Агачлар яки куаклыкларны кисәргә, төпләргә яки утыртырга рөхсәт бирү |
| 6 | Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу |
| 7 | Муниципаль торак фондыннан гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү |
| 8 | Муниципаль торак фондындагы торак урыннарын гражданнарга хезмәт торак урынын найм шартнамәләре буенча бирү |
| 9 | Төзелеп беткән территорияләрне үстерү өчен җир кишәрлекләре бирү |
| 10 | Торак төзелеше максатларында аны комплекслы үзләштерү өчен муниципаль милектә булган җирләрдән җир кишәрлеген арендалау шартнамәләрен төзү хокукын сату буенча торглар оештыру һәм үткәрү |
| 11 | Күчемсез милек объектларына муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү |
| 12 | Җирлектәге муниципаль милектәге биналарны, корылмаларны һәм торак булмаган биналарны арендага бирү |